**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.03.2018 № 184

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 ел, 30 декабрь, 1251 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының “Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча Озак вакытка исәпләнгән программасын раслау турында” 2013 ел, 3 май, 1251 нче карарына Озак вакытка исәпләнгән программаны яңа редакциядә бәян итеп (теркәлә) үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 ел, 19 март, 184 номерлы
карары белән расланды

# Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча Озак вакытка исәпләнгән программасы

## Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча озак вакытка исәпләнгән программасы<br>(алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү турында карар кабул итү өчен нигезләмә | Россия Федерациясе Торак кодексы, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерүне оештыру турында”гы 2013 елның 25 июнендәге 52 нче Законы (алга таба – Закон) |
| Программаны эшләүче | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Халыкка имин һәм кулай яшәү шартлары тудыру. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районындагы торак фондының сакланышын тәэмин итү, яңарту һәм сыйфатын яхшырту, күпфатирлы йортларның техник халәтен яхшырту. |
| Программаның бурычлары | Күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерүне нәтиҗәле итеп планлаштыру һәм оештыру, капиталь төзекләндерү барышында озакка чыдый торган материаллар һәм ресурсны саклый торган технологияләр кулланып, нәтиҗәле һәм комплекслы техник карарлар кабул итүгә ирешү |
| Программаны реализацияләү вакыты | 2014-2043 еллар |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Торак фондын Россия Федерациясе законы таләпләренә туры китерү(шул исәптән, халыкның санитар-эпидемиологик халәте, техник көйләнеш, кулланучыларның хокукларын яклау турындагы закон таләпләренә) |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә |

## I. Мәсьәләнең тасвирламасы

Әлеге Программаны кабул итү өчен күп кенә социаль-икътисадый факторлар алшарт булып тора. Социаль факторлар - яшәү шартларының түбән булуы һәм торак фонд объектларының жимерек хәлдә булуына, ә икътисадый факторлар – аларны тотуга чыгымнарның югары булуына бәйле.

Санап үтелгән проблемаларны хәл итү Татарстан Республикасында “Россия гражданнарына - арзан һәм уңайлы торак” милли проектының иң өстенлекле юнәлеше булып тора. Һәм бу мәсьәләне хәл итү программалы ысулларны кулланып оештыру, җитештерү, социаль-икътисадый һәм башка чаралар комплексын шушы программаны тормышка ашыру вакытында үткәргән, Программаны башкаручыларның эшчәнлеге дәүләт заказчысы тарафыннан тулысынча координацияләнгән очракта гына мөмкин булачак.

## II.Программаның төп максат һәм бурычлары, реализацияләү вакыты һәм Программа үтәлешеннән көтелгән күрсәткечләр

Программаның төп максатлары:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районындагы торак фондының сакланышын тәэмин итү, яңарту һәм сыйфатын яхшырту;

халыкка яшәү өчен куркынычсыз һәм кулай шартлар тудыру.

Программаның бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Программаны башкаручыларны сайлап алу процедураларын ачык һәм халыкка билгеле булырлык итеп үткәрү;

нәтиҗәле техник карарлар кабул итү һәм капиталь төзекләндерү барышында озакка чыдый торган материаллар, ресурсны саклый торган технологияләрнең комплекслы кулланылуына ирешү.

Әлеге Программа 2014-2043 елларда гамәлгә ашырылачак.

Программаны тормышка ашыру түбәндәге эшләрне тәэмин итәргә тиеш:

15850 күпфатирлы йортларда яшәүче гражданнар өчен имин һәм кулай яшәү шартлары тудыру.

## III. Күпфатирлы йортларны Программага кертү шартлары

Программага Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар (Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аварияле һәм сүтелергә тиеш дип табылган йортлардан тыш) керә.

Күпфатирлы йортлардагы гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрү чираты Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында”гы 52нче Законында язылган критерийлар нигезендә Программада билгеләнә.

## IV. Программа чаралары

Программаның төп чаралары:

1. Эксплуатация шартлары камилләштерелгән, озакка чыдый торган материаллар кулланып, күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү һәм башкару:

йорт эчендәге электр, җылылылык, су белән тәэмин итү, суны агызып җибәрү, газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын төзекләндерү яки алыштыру;

куллану өчен яраксыз дип табылган лифт җайланмасын төзекләндерү яки алыштыру, ихтыяҗ булган очракта – лифт шахталарын төзекләндерү;

түбәләрне төзекләндерү; шул исәптән җилләнми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу җайланмалары ясау;

күпфатирлы йортлардагы гомуми милеккә караган подвал биналарын төзекләндерү;

фасадларны җылыту һәм төзекләндерү, халыкның авыр хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүмаксатларында подъездларга керү урыннарын пандуслар белән һәм баскычларны ике яктан култыксалар белән җиһазлау;

ресурслар куллануны исәпләүче гомумйорт приборларын һәм идарә итү узелларын ( җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) кую һәм алыштыру;

фундаментларны төзекләндерү;

күпфатирлы йортның подъездларын төзекләндерү;

күпфатирлы йортта энергетик тикшерүләр үткәрү;

проект документларын эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү (шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы закон нигезендә проект документларын әзерләү таләп ителгән очракта);

төзелешнең барышын контрольдә тоту;

күпфатирлы йортларны янгыннан саклау системасын төзекләндерү;

күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү;

күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составында конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, ремонтлана (алыштырыла) торган конструкцияләр һәм инженерлыксистемаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына кермиторган мөлкәт өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерүне торгызу;

2014 елның 1 июненә кадәр куелган коммуналь ресурслар кулллануны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларын кую (алыштыру) буенча эшләр башкару;

Эксплуатация шартлары камилләштерелгән, озакка чыдый торган материаллар кулланып, күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү эшләрен башкару.

2. Программаны уңышлы итеп тормышка ашыру, нигездә, мәгълүмати-аңлату эшләренең тиешле вакытта, тулы, сыйфатлы һәм үтемле итеп,түбәндәге юллар белән үткәрелүеннән тора:

Программаны реализацияләү барышын республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чараларында: вакытлы матбугат басмаларында (газета-журналларда, шул исәптән, электрон чараларда) радио һәм телеканалларда даими төстә яктырту;

торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыру һәм капиталь төзекләндерү турындагы мәсьәләләрне яктырту максатында махсус теле-радиотапшырулар эшләү;

Нурлат муниципаль районы, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтын актуаль хәлдә тоту;

торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча тематик методик һәм белешмә материалларны бастыру һәм тарату;

торак милекчеләре ширкәте(ТСЖ), торак компаниясе (ЖК), торак һәм торак-төзелеш корпоративлары (ЖСК) һәм идарәче оешмалар (УО) тарафыннан Программага кертелгән күпфатирлы йортларның һәр подъездындагы мәгълүматлар тактасында яки әлеге йортлар урнашкан җир участоклары мәйданында, шулай ук мәгълүмати-телекоммуникацияле “Интернет” челтәре аша сайтларга урнаштыру юлы белән күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрүнең сроклары турындагы мәгълүматны гражданнарга җиткерү.

## V. Программаны гамәлгә ашыру тәртибе

Әлеге Программаны гамәлгә ашыру максатыннан, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Программаны тормышка ашыру буенча бер еллык кыска вакытлы (еллык) планнар раслана.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ел да раслана торган Программаны тормышка ашыру буенча кыска сроклы (еллык) планнар хәзерләү һәм раслау Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча озак вакытка исәпләнгән программасын раслау тәртибе нигезендә башкарыла.

## VI. Программага үзгәрешләр кертү тәртибе

Программаны актуальләштерү елга бер тапкырдан да сирәгрәк булырга тиеш түгел.

Программаны актуальләштерү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Программага кертелгән күпфатирлы йортның Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аварияле һәм сүтелергә тиеш дип билгеләнүе;

күпфатирлы йорт урнашкан җир участогы, әлеге йорттагы һәр торак бүлмәне дәүләт яки муниципаль максатлар өчен алынуның Закон билгеләгән тәртиптә башкарылуы;

күпфатирлы яңа йортларның файдалануга тапшырылуы;

Программага кертелгән күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эш башкару тәртибе үзгәртелүе;

Программага кертелгән күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эш башкару сроклары үзгәртелүе;

Программага үзгәрешләр кертүгә сәбәп булырлык башка нигезләмәләр.

Күпфатирлы йорттагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү срокларын соңрак срокка күчерү, күпфатирлы йорттагы гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәт төрләрен һәм (яки) эш төрләрен кыскарту белән бәйле үзгәрешләрне шушы күпфатирлы йортта яшәүче шәхси милекчеләр тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта гына Программага кертү мөмкин.